ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

18 март, 2021 ел № 6/9

Шәһәр Советының «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итүче күчемсез милеккә караган муниципаль милекне арендалау килешүләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына карата төзелгән җир участогы арендалау килешүләре һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларын аренда килешүләре буенча аренда түләвенә ташлама билгеләү турында» 2020 елның 28 маендагы 39/5 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү турында

«Икътисадның тотрыклы үсешен тәэмин итүгә һәм яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәләрен булдырмый калуга юнәлдерелгән кичектергесез чаралар күрү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 июнендәге 166-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында аеруча зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 11 июлендәге 1032 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы №1497-р һәм 2020 елның 28 декабрендәге 2963-р номерлы боерыклары, Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итүче күчемсез милеккә караган муниципаль милекне арендалау килешүләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына карата төзелгән җир участогы арендалау килешүләре һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларын аренда килешүләре буенча аренда түләвенә

ташлама билгеләү турында» 2020 елның 28 маендагы 39/5 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) исемдә «кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына» сүзләреннән соң «социаль юнәлешле коммерциянеке булмаган оешмалар реестрына кертелгән оешмаларга» сүзләрен өстәргә;

2) 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. 2020 елның апрель – июнь айлары өчен аренда түләве буенча ташламаны Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итүче күчемсез мөлкәткә карата төзелгән муниципаль милекне арендалау шартнамәләре буенча аренда түләвеннән азат итү рәвешендә, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына карата төзелгән җир участокларына арендалау шартнамәләре буенча (алга таба – аренда шартнамәсе) аренда түләвеннән азат итү рәвешендә билгеләргә.».

3) 2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2. Ташлама кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының Бердәм реестрына кертелгән, «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында Россия икътисадының иң күп зыян күргән тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары белән расланган яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начарайган шартларда, аеруча зыян күргән Россия икътисадының бер яки берничә тармагында эшчәнлек алып баручы кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына (алга таба – КУЭ субъекты) 2020 елның 1 апреленә кадәр төзелгән аренда шартнамәләре буенча түбәндәге шартларны үтәгәндә бирелә:

1) Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яисә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага аренда шартнамәсе нигезендә алдагы чор өчен аренда түләве буенча бурыч булмау;

2) аренда шартнамәсендә, яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начарайган шартларда, Россия икътисады тармакларында эшчәнлек төрен (төрләрен) гамәлгә ашыру өчен, аны куллану максатларында, муниципаль күчемсез мөлкәтне арендага бирү каралган булу. Шул ук вакытта, КУЭ субъекты икътисадый эшчәнлекнең төп яки өстәмә төрләре буенча, алар турында мәгълүматның Юридик затларның бердәм дәүләт реестрында яисә шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрында 2020 елның 1 апреленә булган очракта, билгеләнә .»;

4) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2.1 пункт өстәргә:

«2.1. Ташлама 2020 елда Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яйсә гадәттән тыш хәл режимын кертү турында карар кабул ителгәнче, «Социаль юнәлешле коммерциянеке булмаган оешмалар реестры турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 23 июнендәге 906 номерлы карары нигезендә һәм (яисә) «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында аеруча зыян күргән коммерциянеке булмаган оешмалар реестры турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 11 июнендәге 847

номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яйсә гадәттән тыш хәл режимы кертелгән көнгә аренда шартнамәсе буенча узган чор өчен бурычлар булмаганда бирелә.».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш.Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев